**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 10 июлендәге 2448 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 5 маендагы 1547 номерлы «Казан шәһәренең**
**Авиатөзелеш районында ачык сервитут билгеләү турында»гы**
**карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Казанны үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенең Казан шәһәре Башкарма комитетының 2026 елның 5 маендагы 1547 номерлы «Казан шәһәренең Авиатөзелеш районында ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакындагы гаризасын карап тикшергәннән соң **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2026 елның 5 маендагы 1547 номерлы «Казан шәһәренең Авиатөзелеш районында ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.1 пунктчасында «16:50:210202:609» кадастр номерын «16:50:210202:616» кадастр номерына алмаштырырга;

1.2. 1 һәм 2 номерлы кушымталарны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.3. әлеге карарга 1 һәм 2 номерлы кушымталарны, шул ук тәртиптә куеп, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2026 елның 5 маендагы 1547 номерлы карарына 1 һәм 2 номерлы кушымталар дип санарга.

2. «Казанны үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карар нигезендә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан


Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты рәисе Р.Г.Галәветдиновка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 10 июлендәге
2448 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Ачык сервитут йогынтысы өлкәсе чикләре**




| Масштаб: 1:250<br>Координаталар системасы: МСК-16 | |
|---|---|
| Шартлы билгеләр: | |
| 1 | Яңа барлыкка килгән характерлы нокта |
| | Ачык сервитутлар (проектлана торган) |
| | Җир кишәрлекләре |
| | Кадастр кварталлары |
| | Территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар (гамәлдәге) |
| 16:50:210202 | Кадастр кварталы |
| 16:50:210202:616 | Хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |

________________________________